Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Югары Мактама авыл Советы

КАРАРЫ

16 июль 2024 ел № 94

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә

Югары Мактама авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл Советының 2013 елның 25 ноябрендәге 70 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Мактама авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 99 номерлы, 2015 елның 05 маендагы 116 номерлы, 2020 елның 15 маендагы 69 номерлы, 2020 елның 19 ноябрендәге 5 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 83 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктка түбәндәге эчтәлекле алтынчы абзац өстәргә:

«гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә (территорияләргә) карата казна, бюджет һәм автоном учреждениеләр («урам-юл челтәре», «территорияне төзекләндерү» куллану төрләрен кертеп»).»;

1.2. 5 пунктның алтынчы абзацын җиденче абзац дип санарга.

2. Әлеге карарны "Альметьевский вестник" газетасында бастырып чыгарырга, Әлмәт районы, Югары Мактама авылы, Октябрь урамы, 50 нче йорт; Туктар авылы, Кутуй урамы, 9 йорт ; территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Мактама авыл
җирлеге башлыгы Н.Т.Нуриев

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ВЕРХНЕМАКТАМИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1021601632601
Р.05-10978/16
ВЕРХНЕ-МАКТАМИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ
ИНН 1644011306
КПП 164401001